**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

---

**2023 елның 23 октябре** **111-РС номер**

## КАРАР

**«2022-2024 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе турында» 2022 елның 05 декабрендәге 92-РС номерлы Совет карарына үзгәреш һәм өстәмәләр кертү хакында**

Халыкның яшәү сыйфатын һәм тормыш дәрәҗәсен яхшырту максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы **карар чыгарды**:

1. «2022-2024 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе турында» 2022 елның 05 декабрендәге 92-РС номерлы Совет карарына үзгәреш һәм өстәмәләр кертергә, 4 бүлекне тулыландырырга:

- «Татарстан Республикасында берничә юнәлешне: җәйге һәм кышкы спорт төрләрен, сәламәтләндерү, балалар-савыктыру лагерьларын, яшьләр слетларын, спорт ярышларын гамәлгә ашыруны берләштергән бер генә объект та юк. Мондый учреждениене төзү өчен түбәндәге территорияләр сайлап алынган: 3,2 га мәйданлы 16:24:000000:4499 кадастр номеры белән җир участогы, 16:24:0000004498 кадастр номеры белән 1,1439 га мәйданлы җир участогы, Шәһәр яны урманчылыгының Матюшинск участок урманчылыгының 50 нче кварталының 36,39,40,42 бүлеп бирү өлешендә, урман фонды җирләренә караган,16:24:000000:4499 җир участогын 16:24:0000004498 футбол кыры белән тоташтырган Шәһәр яны урманчылыгының Матюшинск участок урманчылыгының 50 нче кварталының 40,58,51,59,61 бүлеп бирү өлешендәге 16:24:000000:5793 кадастр номерлары белән гомуми мәйданы 1,1254 га булган җир участогы, Әлеге объектны булдыру балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда дәвамлылыкны тәэмин итәчәк, балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләнүен оештыру өчен кирәкле шартлар тудырачак.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык - муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**